| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**КАРАР** **КАРАР**

2022 елның 18 ноябре Кукмара ш. № 160

«Кукмара муниципаль районының җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибе турындагы нигезләмә хакында» Кукмара район Советының 2010 елның 26 мартындагы 14 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожск өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләренә Россия Федерациясе дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны, федераль дәүләт граждан хезмәткәрләрен, федераль дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче федераль дәүләт органнары хезмәткәрләрен командировкага җибәрүнең үзенчәлекләре турында» Россия Федерациясе Президентының 17.10.2022 елның 17 октябрендәге 752 номерлы Указының 4 пункты нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Кукмара район Советының 2010 елның 26 мартындагы 14 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнарында командировкага җибәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә (Кукмара муниципаль район Советының 15.08.2012 елның 15 августындагы 149 номерлы, 2022 елның 27 маендагы 125 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 14.1 пунктын өстәргә:

«14.1. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, муниципаль хезмәткәрләргә, муниципаль хезмәт вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренә Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожск өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә хезмәт командировкаларында булган чорда:

а) акчалата түләү (акчалата хезмәт хакы) икеләтә күләмдә түләнә;

б) даими яшәү урыныннан читтә яшәү белән бәйле өстәмә чыгымнар (тәүлеклек) хезмәт командировкасында булган һәр көн өчен 8480 сум күләмендә каплана;

в) җирле үзидарә органнары мондый командировкалар белән бәйле өстәмә чыгымнарны каплау максатларында хисап бирелми торган суммалар түләргә мөмкин.»;

1.2. 6 – 9, 20 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

1.3. 24 пунктта «Россия Федерациясе территориясе чикләреннән тыш командировкада буларак рәсмиләштерелгән командировка таныклыгындагы билгеләргә» сүзләрен «юл документларына (билетларга)» сүзләренә алмаштырырга.»

1.4.30 пунктның «а» пунктчасында «тиешенчә рәсмиләштерелгән командировка таныклыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

2. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитетына ведомство карамагындагы учреждениеләр хезмәткәрләре өчен әлеге карарда каралган шартларга охшаш командировка шартларын билгеләүне тәэмин итәргә киңәш итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев